# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2022 елның 31 марты №87

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында

Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Гыйниятов А.М. мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы нигезендә, иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Генераль планын расларга (карталар һәм текст өлеше кушымтада бирелә).

2. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип санау турында:

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2012 елның 28 декабрендәге 104 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау (үзгәрешләр кертү) турында» 2015 елның 16 июнендәге 153 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.б., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ административ бинасында мәгълүмат стенды, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

Башлык урынбасары
Шәһәр тибындагы бистә
Карамалы Тау

А.А. Абдуллин